кулларындагы тупларын ыргыталар. Ераграк ыргыткан бала мактала. Тупны ыргыткан балалар туплары артыннан йөгереп баралар да аны артларында торучыларга бирәләр.

Уенга күрсәтмәләр

• Нинди ераклыкта ыргытуны белү өчен, уйнаучылар алдындагы җирдә 2–3 метр ераклыкта берничә сызык сызып куела.

• Уң һәм сул кул белән ыргытырга кирәк.

• Уен 4–6 тапкыр кабатлана.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “4нче номерлы “Ләйсән” гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы”

***Уйный***

***Үсәбез***

***Уйный***



## Күз бәйләш

Уйнаучылар түгәрәкләнеп тезеләләр, түгәрәкнең уртасында ике бала басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, ә икенчесенә кечкенә кыңгырау бирәләр. Беренче бала кыңгырау тавышы буенча иптәшен тотарга тырыша, ә икенчесе ничек булса да тоттырмаска тырыша. Ул тотылганнан соң, түгәрәк уртасына башка балалар керәләр.

## Узышчылар

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Уйнаучылардан 20–25 м ераклыкта сызык үткәрелә яисә бу урын флаглар белән билгеләнә. Уйнаучылар барысы бергә: «Бер, ике, өч!» – дип кычкыралар. Шуннан соң беренче булып басып торган ике бала флагларга кадәр йөгереп барып, кире йөгереп әйләнеп  кайталар. Икесе дә бер-берсен узарга тырыша. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, аннан соң икенче пар йөгерә.
Уенга күрсәтмәләр

• Тәрбияче балаларның сигнал булганнан соң гына йөгерешеп китүләрен һәм билгеләнгән урынга барып җитүләрен күзәтергә тиеш.
• Парларны көчләре ягыннан тигез булуларын исәпкә алып сайларга кирәк.

## Коткаручы таяк

Бер бала әйдәүче (уенны алып баручы) итеп билгеләнә. Ул, битен куллары белән каплап, уйнаучыларга арты белән стена кырыена баса. Аның янында коткаручы таяк ята. Әйдәүче 15–20 гә кадәр саный, бу вакытта башка балалар качалар. Әйдәүче, санап бетергәч, күзен ачып, таяк белән тукылдата-тукылдата: «Таяк килде, беркемне дә тапмады!» – ди һәм качкан балаларны эзләргә китә. Әйдәүче берәр баланы күрү белән, ул да, бала да, берсен берсе куып, коткаручы таяк янына йөгерешеп киләләр. Кем беренче килеп җитэ, шул таяк белән тукылдата. Әйдәүче таяк янына беренче килеп җитсә, табылган баланың исемен әйтеп: «Коткаручы таяк Алмазны тапты!» – ди. Әгәр эзләп табылган бала таякны беренче килеп тукылдатса, ул: «Коткаручы таяк, коткар мине!» – ди. Әйдәүче балаларны эзләгән вакытта, һәр качкан бала, уңайлы моментны сайлап, таяк янына йөгереп килеп, аның ярдәмендә котылырга тырыша. Әйдәүче һәрвакыт йөгеүче баланы узып, таяк янына беренче булып килергә тырыша. Әгәр качкан баланың иң соңгысы таяк янына әйдәүчедән алда йәгереп килеп җитсә ул: «Коткаручы таяк, барыбызны ды коткар!» – ди. Мондый очракта әйдәүче үз ролен яңадан үти. Әгәр таяк янына әйдәүче алдан килеп җитсә, ул вакытта коткарыла алмаган балаларның беренчесе киләчәк уенда коткаручы була.

## Кем ераграк ыргыта?

Уйнаучылар 2 яки 3 рәткә тезеләләр. Мәйданның киңлегенә карап, һәрбер рәттә 7–8 кеше була. Беренче рәттә басып торучыларның кулларында туп. Алар, тәрбияченең «Башлагыз!» дигзн сигналына карап,